РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 1 » июль 2022 ел г. Альметьевск № 1328

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында» 2021 елның 12 гыйнварындагы 01 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы, «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә» 2020 елның 27 июлендәге 1120 номерлы карарлары һәм Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2022 елның 20 маендагы 02-08-02/554 номерлы күрсәтмәсе

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча ведомствоара комиссия турында» 2021 елның 12 гыйнварындагы 01 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 октябрендәге 1506 номерлы, 2022 елның 16 маендагы 896 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

комиссия составына кертергә:

Р.И. Хөсәеновны – комиссия әгъзасы, Әлмәт районында һәм Әлмәт шәһәрендә Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге

Зак. № 305-2000

башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча);

А.Р. Алимовны – комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Әлмәт районындагы һәм Әлмәт шәһәрендәге Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча).

2. Элеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов